**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2023 ел** **№8**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 29 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ямбулат-Пустошь авылы, Яшел урамы, 16 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала,Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Ямбулат-Пустошь авылында вак таш белән таш белән юлларны түшәү, төзү, карап тоту, төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

- Ямбулат-Пустошь авылындагы юлларны кышкы-җәйге тоту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-Ямбулат-Пустошь авылында һәйкәл төзү һәм төзекләндерү, граниттан мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: Ф.Х.Гарифуллина